**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2024 елның 12 апреле 251№

Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында»гы 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 10 июлендәге " Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында" 286 номерлы федераль законнары, 2023 елның 02 нояберендәге " Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 99-ЗРТ номерлы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районы Уставы белән, Әлки муниципаль район Советы **Карар итте:**

1. Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында»гы 63 номерлы карарына (2017. 04.08, 115№, 2017.15.11, 131№, 15.11.2018 196№, 12.04.2019 232№, 10.25.2019 269№, 19.03.2020 296№, 28.08.2020 319№, 23.10.2020 14№, 29.07.2021 64№, 2023.03.23 161№ , 181 № 2023.07.14 , 234 № 2023.12.15 редак.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

"12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада аңа билгеле булган мәгълүматларның үзгәрүе турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкета).";

3.5.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;";

4 нче бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.1.1 пункты белән тулыландырырга:

"4.1.1 Анкетаны тәкъдим итү, анкетадагы мәгълүматның үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү

4.1.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тәкъдим итә.

4.1.2. Муниципаль хезмәткәр яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

4.1.3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4.1.4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган җәмәгать хакимияте органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.".

4.1.3 пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерергә:

"2) 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;";

4.1.4 Пункт "мәгълүмат" сүзеннән соң "(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)"сүзләре белән тулыландырырга;

8 нче бүлекнең 11 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;";

түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт белән тулыландырырга:

"11.1 дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;"

8.1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8.1.7. Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар катнаша ала.".

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматның порталында бастырырга (//htth:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль
районы Башлыгы

А.Ф.Никошин